**ГЛАВА**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШЛЫГЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

07.07.2023 Балык Бистәсе штп. № 14рг

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибе турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсе нигезендә:

1. Гражданнарның Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратына кергән мөрәҗәгатьләрен анализлауның кушымтада бирелгән тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының оештыру бүлеге башлыгы урынбасарына гражданнарның мөрәҗәгатьләрен елына ике тапкыр, яртыеллыкның ахыргы аеннан соң килүче айның 10 нчы көненә хәтле анализларга (алга таба – анализ).

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлек башлыгы урынбасарына (мәгълүмати куркынычсызлык һәм мәгълүмати технологияләр буенча) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми сайтында яртыеллыкның ахыргы аеннан соң килүче айның 15 нче көненнән дә соңга калмыйча анализ урнаштыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге боерыкны (күрсәтмәне) Татарстан Республикасы Балык - Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Әлеге боерыкның (күрсәтмәнең) үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Ф.М. Вафинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Башлыгының
2023 елның 07 июле
14 рг номерлы боерыгы
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсен, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 маддәсен үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләрне) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын (алга таба – Совет аппараты) билгели.

2. Анализ үткәрелгәндә килгән, адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең саны, электрон документ әйләнеше рәвешендә мөрәҗәгатьләр, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны турында мәгълүмат, гражданнарны шәхсән кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турындагы мәгълүмат (булган очракта) өйрәнелә.

3. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә бирелә торган электрон документлар әйләнеше һәм мәгълүматлар нигезендә Совет аппаратының (алга таба - бүлек) оештыру бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының, аның урынбасарының, Совет аппараты җитәкчесенең, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (алга таба - Совет аппараты җитәкчелеге, гражданнарны кабул итү буенча вәкаләтле затлар) шәхсән кабул итүендә кергән мөрәҗәгатьләр турында мәгълүмат Совет аппаратының эш башкаручысы тарафыннан бүлеккә бирелә, ул гражданнарны Совет аппараты җитәкчелеге, гражданнарны кабул итү буенча вәкаләтле затлар тарафыннан шәхсән кабул итүгә яздыра.

5. Күчмә кабул итүләр буенча мәгълүмат шулай ук Совет аппаратының эш башкаручысы тарафыннан бүлеккә бирелә.

6. Әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат Совет аппаратының эш башкаручысы тарафыннан яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 5 нче көненә кадәр бүлеккә бирелә.

7. Бүлек башлыгы урынбасары 3 нче пунктта күрсәтелгән, шулай ук әлеге Тәртипнең 4 нче һәм 5 нче пунктларына ярашлы рәвештә кергән мәгълүматны ике эш көне дәвамында гомумиләштерә һәм анализны Совет аппараты җитәкчесе белән килештерә.

8. Мөрәҗәгатьләрнең анализы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгълүмати куркынычсызлык һәм мәгълүмати технологияләр буенча урынбасарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районының рәсми сайтында урнаштыру өчен җибәрелә. Анализ Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында яртыеллыкның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.

9. Совет Аппаратында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адрес буенча ачык мәгълүмат булып тора.